Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

## Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2004 елның 11 ноябрендә
кабул ителде

Әлеге Закон халыкны һәм территорияләрне муниципальара һәм төбәк характердагы табигый, техноген һәм биологик-социаль гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Әлеге Законның гамәли көче муниципальара һәм төбәк характердагы гадәттән тыш хәлләрне (алга таба – гадәттән тыш хәлләр) кисәтү, гадәттән тыш хәлләрдән килгән зыян һәм югалтулар күләмнәрен киметү, гадәттән тыш хәлләрдә халыкның яшәешен тәэмин итү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү өлкәсендә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм халыкның эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә кагыла.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

гадәттән тыш хәл – кешеләр үлеменә китерерлек яисә китергән, кешеләрнең сәламәтлегенә һәм (яисә) әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян, шактый зур матди югалтуларга һәм кешеләрнең тормыш эшчәнлеге шартлары бозылуга китерерлек яисә китергән табигый, техноген, биологик-социаль гадәттән тыш хәлләрнең чыганаклары барлыкка килү нәтиҗәсендә билгеле бер территориядә килеп туган хәл;

табигый гадәттән тыш хәл – кешеләр үлеменә китерерлек яисә китергән, кешеләрнең сәламәтлегенә һәм (яисә) әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян, шактый зур матди югалтуларга һәм кешеләрнең тормыш эшчәнлеге шартлары бозылуга китерерлек һәм китергән табигый гадәттән тыш хәл чыганагы барлыкка килү нәтиҗәсендә билгеле бер территориядәге яисә акваториядәге хәл;

техноген гадәттән тыш хәл - объектта, билгеле бер территориядә яисә акваториядә техноген гадәттән тыш хәл чыганагы барлыкка килү нәтиҗәсендә кешеләрнең нормаль тормыш эшчәнлеге шартлары бозылуга, аларның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янауга, халыкның мөлкәтенә, халык хуҗалыгына һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китерерлек хәл;

биологик-социаль гадәттән тыш хәл – билгеле бер территориядә биологик-социаль гадәттән тыш хәл чыганагы барлыкка килү нәтижәсендә кешеләрнең нормаль тормыш эшчәнлеге шартлары бозылуга, авыл хуҗалыгы терлекләре үрчетүнең һәм үсемлекләр үсешенең нормаль шартлары бозылуга, кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янауга, йогышлы авыруларның киң таралуына, авыл хуҗалыгы терлекләре һәм үсемлекләре кырылуга китерерлек хәл;

гадәттән тыш хәл зонасы - гадәттән тыш хәл барлыкка килгән территория;

хәвефле табигый процесслар һәм күренешләр мониторингы – әйләнә-тирә табигать мохитендәге хәвефле табигый процессларның һәм күренешләрнең күбәюен, аларны барлыкка китерүче һәм күбәйтүче факторларны билгеле бер программа нигезендә даими рәвештә күзәтеп һәм тикшереп тору системасы;

гадәттән тыш хәлләрне фаразлау – гадәттән тыш хәлләрнең барлыкка килү һәм күбәю ихтималын билгеләүгә юнәлдерелгән гамәлләр системасы;

гадәттән тыш хәлләрдә халыкнын яшәешен тәэмин итү – гадәттән тыш хәл зонасында, эвакуация маршрутларында һәм зыян күргән халыкны күчереп урнаштырган урыннарда кешеләрнең яшәешен тәэмин итү һәм сәламәтлеген саклау өчен кирәкле шартлар тудыруга юнәлдерелгән, башкарма хакимият органнары, жирле үзидарә органнары тарафыннан уздырылучы гамәлләр җыелмасы;

гадәттән тыш хәлләрне бетерү – гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә уздырыла торган һәм кешеләрне үлемнән коткаруга һәм аларның сәламәтлеген саклауга, әйләнә-тирә табигать мохитенә китерелгән зыян күләмнәрен, матди югалтуларны киметүгә, шулай ук гадәттән тыш хәл зоналарын локализацияләүгә, гадәттән тыш хәлләр өчен характерлы булган хәвефле факторларның йогынтысын туктатуга юнәлдерелгән һәлакәттән коткару эшләре һәм башка кичектергесез эшләр.

### 2 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый жайга салу**

Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу федераль законнар, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив хоукый актлар белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат**

Әгәр законнарда башкасы каралмаса, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат хәбәрдар һәм ачык була.

Дәүләт хакимияте органнары, жирле үзидарә органнары, оешмалар халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау чаралары турында, фаразланучы һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша, мөмкин булган башка ысуллар белән ашыгыч рәвештә һәм дөрес мәгълүмат бирергә тиеш.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәгълүмат белән халыкны, дәүләт хакимияте органнарын, жирле үзидарә органнарын һәм оешмаларны тәэмин итү тәртибе Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

4 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау принциплары**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау түбәндәге принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла:

законлылык;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен хәл иткәндә дәүләт хакимияте органнары, жирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеген катгый регламентацияләү;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә, шулай ук алар барлыкка килгәндә күргән зыян һәм югалтулар күләмнәрен мөмкин кадәр максималь киметүгә юнәлдерелгән гамәлләрне вакытында уздыру;

территорияләрнең икътисадый, табигый һәм башка үзенчәлекләрен, шулай ук гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычының реаль мөмкинлек дәрәҗәсен исәпкә алу;

көчләрнең һәм чараларның җитәрлек булуы зарурлыгы, булган көчләрдән һәм чаралардан мөмкин кадәр күбрәк файдалану;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен хәл иткәндә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның иҗтимагый оешмалар һәм халык белән үзара хезмәттәшлеге;

халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек.

5 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау гадәттән тыш хәлләр шартларында яисә аларның барлыкка килүнең реаль куркынычы булган очракларда кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч янауны, әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян килүне кисәтүгә, бетерүгә яисә киметүгә, шулай ук моның өчен кирәкле көчләр һәм чаралар булдыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең өстәмә территориаль системасының килештерелгән (уздыру урыны һәм вакыты, максатлары, ресурслары буенча) гамәлләр комплексын уздыру юлы белән башкарыла.

6 статья. **Гадәттән тыш хәлләрдә халыкның яшәешен тәэмин итү**

Гадәттән тыш хәлләрдә халыкның яшәешен тәэмин итү гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен билгеләнгән финанс һәм матди ресурсларның резервлары исәбеннән башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Гадәттән тыш хәлләрне бетерү**

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, оешмалар, җирле үзидарә органнары, көчләре һәм чаралары белән гамәлгә ашырыла. Югарыда күрсәтелгән көчләр һәм чаралар җитешмәгәндә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимиятнең федераль органнары көчләре һәм чаралары җәлеп ителә.

## II бүлек. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары компетенциясе

8 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясе**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә законнар белән җайга салу;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә аеруча мөһим республика программаларын раслау;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнарның үтәлешен тикшереп тору.

9 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты компетенциясе**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә норматив хокукый актлар кабул итү;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм аларны әзерлектә тотуны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән хәлләрдә халыкны яклану ысулларына һәм гамәлләренә өйрәтү;

гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация гамәлләрен үткәрү турында карарлар кабул итү һәм аларны үткәрүне тәэмин итү;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат җыюны һәм алмашуны гамәлгә ашыру, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы яисә килеп чыгу турында халыкка вакытында хәбәр итү;

һәлакәт-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру, шулай ук аларны үткәргән вакытта җәмәгать тәртибен саклау;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә финанслауны гамәлгә ашыру;

гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларнын резервларын булдыру;

гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшчәнлегенә ярдәм итү.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә махсус вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясе**

Җирле үзидарә органнары компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклауны тәэмин итү өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны әзерләү һәм әзер килеш тоту;

гадәттән тыш хәлләрдә халыкны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртип нигезендә яклану алымнарына һәм гамәлләренә өйрәтү;

гадәттән тыш хәлләрдә халыкны һәм территорияләрне яклауны тәэмин итү гамәлләрендә катнашу;

гадәттән тыш хәлләрдә халыкның яшәешен законнар нигезендә тәэмин итү;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат җыюны һәм алмашуны гамәлгә ашыру;

гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның резервларын булдыру;

гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы турында яисә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу турында халыкка вакытында хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне тәэмин итү;

гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын уздыру турында карарлар кабул итү һәм шушы чараларны уздыруны оештыру;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге гамәлләрне финанслауны гамәлгә ашыру;

һәлакәт-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру һәм уздыру, шулай ук аларны үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклау;

көчләр һәм чаралар житешмәгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына ярдәм сорап мөрәҗәгать итү;

гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшчәнлегенә булышу;

жирле үзидарә органнары каршында халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче идарә органнары булдыру;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

## III бүлек. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә дәүләт идарәсе

### 11 статья. **Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы**

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнен һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы төзелә.

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы турындагы нигезләмә һәм аның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

12 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге һәм тикшереп торуы**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге һәм тикшереп торуы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү эшләрен башкару күләмен, гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда урындагы затларның, көчләрнең һәм чараларның аларны бетерү эшләренә әзерлек дәрәҗәсен билгеләү максатларында Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасына йөкләнгән бурычларга туры китереп үткәрелә.

Бу өлкәдә дәүләт күзәтчелеге һәм тикшереп торуы федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

13 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә дәүләт экспертизасы**

Гадәттән тыш хәлләрнең чыганаклары булырлык яисә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклауны тәэмин итүгә йогынты ясарлык житештерү һәм социаль билгеләнештәге объектлар буенча гамәлгә ашырылуы күз алдында тотылган проектларга һәм карарларга дәүләт экспертизасы аларның билгеләнгән нормаларга, стандартларга һәм кагыйдәләргә туры килү-килмәү дәрәҗәсен тикшерү һәм ачыклау максатларында башкарма хакимият органнары тарафыннан оештырыла һәм уздырыла, Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кирәк чакта гадәттән тыш хәлләрнең чыганаклары булырлык яисә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклауны тәэмин итүгә йогынты ясарлык җитештерү һәм социаль билгеләнештәге объектлар буенча гамәлгә ашырылуы күз алдында тотылган проектларга һәм карарларга экспертиза Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый берләшмәләр һәм бәйсез экспертлар, шулай ук халыкара эксперт оешмаларының белгечләре тарафыннан уздырыла ала.

14 статья. **Хәвефле табигый процесслар һәм күренешләр мониторингы һәм гадәттән тыш хәлләрне фаразлау**

Хәвефле табигый процессларга һәм күренешләргә бәйле гадәттән тыш хәлләрне кисәтү гамәлләрен вакытында әзерләү һәм үткәрү, алар аркасында китерелгән зыянны киметү максатында хәвефле табигый процесслар һәм күренешләр мониторингы гамәлгә ашырыла.

Табигый гадәттән тыш хәлләрне фаразлау - хәвефле геологик, атмосфера, гидрологик процесслар һәм күренешләр, шулай ук табигый янгыннар килеп чыгу һәм таралу ихтималын билгеләү.

Техноген гадәттән тыш хәлләрне фаразлау - янгыннар, шартлаулар, һәлакәтләр һәм бәла-казалар килеп чыгу куркынычын бәяләү нигезендә

техноген гадәттән тыш хәлләр һәм аларның нәтиҗәләре килеп чыгу һәм таралу ихтималын алдан чагылдыру.

Биологик-социаль гадәттән тыш хәлләрне фаразлау - эпидемияләр, эпизоотияләр, эпифитотияләр һәм аларның нәтиҗәләре килеп чыгу ихтималын һәм таралу масштабларын билгеләү, ул түбәндәге гамәлләрне әзерләү һәм нигезләү максатларында үткәрелә:

кешеләр арасында йогышлы авырулар таралышын кисәтү, кешеләрнең гомуми йогышлы авырулар белән авыруларын киметү һәм эпидемияләр аркасында килеп чыккан социаль-икътисадый зыяннарны бетерү;

авыл хуҗалыгы терлекләренең йогышлы авырулары таралышын кисәтү, авыл хуҗалыгы терлекләренең гомуми йогышлы авыруларын киметү һәм эпизоотияләр аркасында килеп чыккан социаль-икътисадый зыяннарны бетерү;

авыл хуҗалыгы үсемлекләренең йогышлы авырулары һәм корткычлары таралышын кисәтү, эпифитотияләр аркасында килеп чыккан социаль-икътисадый зыяннарны бетерү.

Хәвефле табигый процесслар һәм күренешләр мониторингы һәм гадәттән тыш хәлләрне фаразлау халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Гадәттән тыш хәлләр мониторингы һәм аларны фаразлау нәтиҗәләре гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм гадәттән тыш хәлләр вакытындагы гамәлләрне планлаштыру чараларын күрү турында карарлар кабул итү өчен нигез булып тора.

## 15 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә оешмаларның бурычлары**

Оешмалар халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә федераль законнарда каралган гамәлләрне башкарырга бурычлы.

## 16 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту тәртибе**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту тәртибе федераль закон нигезендә билгеләнә.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту оешмаларда, шул исәптән мәгариф учреждениеләрендә, шулай ук яшәү урыны буенча гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның җитәкчеләре һәм башка хезмәткәрләре гадәттән тыш хәлләрдәге гамәлләргә әзерлекне урта һөнәри һәм югары һөнәри белем

учреждениеләрендә, өстәмә белемнең мәгариф учреждениеләрендә (квалификация күтәрү учреждениеләрендә, курсларда, һөнәри юнәлеш үзәкләрендә һәм тиешле лицензиясе булган башка учреждениеләрдә) һәм турыдан-туры эш урынында узалар.

17 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалау**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалау басма продукция бастырып чыгару һәм тарату, тематик телевизион һәм радиопрограммалар тапшыру, күргәзмәләр, симпозиумнар, конференцияләр оештыру һәм халыкка мәгълүмат бирүнең законнар белән тыелмаган бүтән рәвешләреннән файдалану юлы белән массакүләм мәгълүмат чаралары аша гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалау башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан тәэмин ителә.

18 статья. **Гадәттән тыш хәлләрне бетерүдә иҗтимагый берләшмәләрнең катнашуы**

Иҗтимагый берләшмәләр халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклауны тәэмин итү чараларында законнар һәм үз уставлары нигезендә катнаша алалар.

## IV бүлек. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә финанс белән тәэмин итү

19 статья. **Гадәттән тыш хәлләрне кисәтүне һәм бетерүне финанс белән тәэмин итү**

Төбәк һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча федераль законда билгеләнгән гамәлләрне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе була.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә махсус вәкаләтле дәүләт органнарының эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү федераль закон нигезендә Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе була.

20 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге максатчан программаларны финанслау**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге максатчан программаларны финанслау законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

21 статья. **Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, гадәттән тыш хәлләрдә халыкнын яшәешен тәэмин итү өчен билгеләнгән финанс чараларының һәм матди ресурсларның резервларын булдыру һәм алардан файдалану**

Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның резервлары гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу очрагында кирәкле чараларны кичекмәстән җәлеп итү максатларында вакытыннан алда булдырылалар. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекләр финанс һәм матди ресурсларының резервлары тиешенчә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан булдырылалар.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән резервларны (резерв фондларын) булдыру һәм алардан файдалану тәртибе һәм шушы резервларның файдаланылган чараларын янадан торгызу тәртибе тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.

## V бүлек. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык

22 статья. **Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнарны бозган өчен җаваплылык**

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге законнарны бозган өчен урындагы затлар, гражданнар һәм оешмалар законнар нигезендә җаваплы булалар.

**VI бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре**

23 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү турында**

Әлеге Закон 2005 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан,Кремль
2004 елның 8 декабре

№ 62-ЗРТ